# *Низамиева Диләрә Һади кызы.*

*Сугыш башланганда энем бар иде  минем, кызамык авыруыннан  үлде. Әни ничә тапкыр әти янына Суслангерга барып йөрде. Анда сохарилар киптереп, вентовка тотарга перчатка бәйләп баралар иде. Әни 3-4 тапкыр барган.*

*Сугыш вакытында безгә әни көч бирде, ачка тилмертмәде. Күкәрин ашасак та, бәрәңгебез булды. Колхозда әниләр бәрәңге алганга ат йөге белән бәрәңге кертәләр иде, шуңа без бәрәңгегә аптырамадык, кеше шикелле кычыткан, кузгалак ашлары ашамадык. Дәүәти дә  такта яра иде, ул да тормыш алып барырга ярдәм итте.*

*45 нче елның  сугыш беткән көннәрендә безгә кара кайгы килде. Әтинең “публигы” килеп төште: 44 нче елнең 22 нче апрелендә әти Польшада үлгән.*

*Сугыш вакытында мин мәктәптә укый идем. Сугыш беткәч, укытучы Хафизова Сафия апа, җәйгә чыгу белән тары,бодай чүбенә алып чыга иде. Казан юлына чүп утарга алып барды. Бер елны каткан кантар бик күп иде, олылар белән беррәттән, китмән түтәсе белән шуны ватарга чыктык. Җәй, эссе көн, бөтен басу иңләп кеше.*

*Зур Битаман урта мәктәбендә укыдым, мәктәп җылы, лампа яндыралар иде класста. 600 дән артык бала булгандыр инде. Битаман балалары икенче сменада укыйлар иде. Караңгыда лампа белән шәмнәр алып төшеп укый идек. Укытучылар грифль тактасы бирделәр.*

*Сугышчыларга карт әниләр бәрәңге киптереп жибәрәләр иде.  Вентовка тотарга перчаткалар бәйләп жибәргәннәр. Кич утырып оекбашлар бәйләгәннәр.*

*Сугыш бетү турында әтинең публигы килгәч ишеттек. Кеше бәйрәм итте, безнең әни тәгәрәп елады.*

*Сугыш вакытында сыер бар иде, сыер булгач, катык, каймак, творог ясап ашадык, тавыклар бар иде. Укырга  китаплар, сөт, йомырка сатып ала идек, әни срогы чыккан китаплар алып кайта иде  Казаннан. Тормыш бик авыр иде.*

*Яшьләргә теләгем шул: еллар имин, тыныч булып, тынычлык белән яшәсәләр иде.*